МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ**

**БОЕРЫК**

22.04.2026

Казан ш.

№ 466-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының "Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссиясе турында нигезләмәне раслау турында" 02.07.2024 № 414-пр боерыгына үзгәрешләр кертү турында

"Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәве һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссияләр турында" Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы № УП-569 Указы нигезендә б о е р а м:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының "Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссиясе турында нигезләмәне раслау турында" 02.07.2024 № 414-пр боерыгына (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 29.04.2025 № 240-пр, 08.07.2025 № 407-пр, 11.12.2025 № 716-пр боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Атаманы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссиясен төзү турында”.

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссиясен төзергә.»;

Түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт белән тулыландырырга:

«$1^1$. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссиянең беркетелгән нигезләмәсен һәм аның составын расларга.»;

боерык белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссиясе турында нигезләмәдә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Комиссия Министрлык боерыгы белән төзелә. Күрсәтелгән боерык белән Комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, сәркатип билгеләнә һәм Комиссиянең башка әгъзалары тәгаенләнә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карар кабул иткәндә тигез хокуклы. Комиссия рәисе югында аның бурычларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

2.2 пунктның «а» подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) министр урынбасары (Комиссия рәисе), Министрлыка дәүләт хезмәте вазифасын биләүче зат (Комиссия рәисе урынбасары), Министрлыкның кадрлар бүлегенең коррупцияне һәм башка хокук бозуларны кисәтү эшенә җаваплы вазифаи заты (Комиссия сәркатибе), Министрлыкның кадрлар бүлеге, хокук идарәсе, Министрлыкның министр билгеләгән башка бүлекчәләре дәүләт хезмәткәрләре;»;

3.1 пунктның «а» подпунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге № УП-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъва иткән гражданнарга үз керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр

тапшыруы турында Нигезләмәдә каралган белешмәләрнең дәүләт хезмәткәре тарафыннан дөрес һәм тулы тапшырылмавы;»;

3.11 пунктның «а» подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан 2009 елның 30 декабрендәге № ПУ-702 Татарстан Республикасы Президенты Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында нигезләмә нигезендә тапшырылган белешмәләрнең ышанычлы һәм тулы булуын билгеләргә;».

Министр в.б. А.И.Галиев